Сафина, Ф. Сәйләннән калфак чиктеләр: [Туган якны өйрәнү һәм татар әдәбияты бүлеге / Ф. Сафина, Р. Шайхуллина// Шәһри Чаллы. – 2024. - № 70 (2 октябрь). – Б. 3.

# Сәйләннән калфак чиктеләр



/ ФОТО ШӘҺӘР ҮЗӘК КИТАПХАНӘСЕННӘН

Безгә язалар

**Һәр ел саен 1 октябрьдә дөнья-күләм өлкәннәр көне билгеләп үтелә.** Бу уңайдан Яр Чаллы шәһәр үзәк китапханәсенең «Туган якны өйрәнү һәм татар әдәбияты» бүлегендә өлкәннәр көненә багышланган «Сәйләннәрдән калфак чигәм» дип исемләнгән түгәрәк өстәл үткәрелде. Бу очрашуда өлкән буын кешеләре үзләренең чигү, тегү сәләтләре белән уртаклашып, яшьлекләрен искә алдылар. Алар татар хатын-кызларына хас тыйнаклык, тырышлык белән үзләренә түбәтәй чиктеләр. Нәтиҗәдә бик тә матур, үзенчәлекле иҗади эшләр килеп чыкты.

Көзләр килү – зур бәйрәм ул,
Көзләр килү тамаша.
Шул көздәге матурлыктан
Минем күзләр камаша.
Көзнең тагын матурлыгы
Өлкәннәр көне белән!
Өлкәннәргә озын гомер, исәнлек!
Бәйрәм белән!

**Фирдәвес Сафина,**
**Руфия Шәйхуллина,**
**китапханәчеләр.**